| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ<br>КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ТЕЛӘЧЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | с. Тюлячи | КАРАР |
|---|---|---|
| «27» март 2023г. | | № 64 |

Теләче муниципаль районында торак пунктлар территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 14 мартындагы 625-р номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, әйләнә-тирә мохитне саклау, шулай ук торак пунктлар, предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр территорияләрен, гомуми файдалану урыннарын һәм юл яны полосаларын, автомобиль юлларын төзекләндерү һәм аларны экологик һәм санитар-эпидемиологик куркынычсызлык таләпләренә җавап бирә торган хәлгә китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә торак пунктлар территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык игълан итәргә (алга таба текст буенча - Икеайлык).

2. Икеайлыкны үткәрү буенча район штабын төзергә һәм аның составын 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.

3. Икеайлыкны үткәрү буенча чаралар планын 2 номерлы кушымта нигезендә расларга.

4. Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- элек ачыкланган рөхсәтсез калдыклар ташлау урыннарын бетерү буенча чаралар күрү;

- рөхсәтсез калдыклар ташлау урыннары барлыкка килүне булдырмау;

- төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен һәм җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен үтәү;

- паркларны, балалар мәйданчыкларын, халык күпләп ял итә торган урыннарны, шәхси торак сектор территорияләрен, күп фатирлы йортлар янындагы территорияләрне санитар чистарту буенча чаралар үткәрү;

- биологик калдыкларны (үләт базларын) тиешенчә карап тоту һәм эксплуатацияләү һәм алар янәшәсендәге урыннарны санитар чистарту.

5. Авыл хуҗалыгы предприятиеләре, оешмалары житәкчеләренә терлекчелек калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

6. «ТАТМЕДИА» АЖ филиалы ТеләчеИнформ мәгълүмат үзәгенә (Хужин Л.Ю.) ике айлык үткәрү чорында район территориясендә эшне даими яктыртуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлеевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«27» 03 2023 № 64
карарына 1 номерлы кушымта

Торак пунктлар территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик Икеайлык үткәрү буенча район штабы составы

Штаб башлыгы:

| | | |
|---|---|---|
| Хәмидуллин И.Х. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе. |

Штаб секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Насыйбуллина В.Г. | - | балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторының баш белгече, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар арасында гаилә җитешсезлекләрен һәм хокук бозуларны профилактикалау инспекторы. |

Штаб әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Хәбибуллина Л.В. | - | Саба районындагы «Роспотребнадзор» территориаль Идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Зарипов И.С. | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Хәкимуллин Л.М. | - | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча күзәтчелек эше идарәсе баш белгече (килешү буенча); |
| Вәлеев Ф.С. | - | район Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| Билалов Р.М. | - | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының үзәк территориаль идарәсе дәүләт инспекторы(килешү буенча); |
| Гарипов И.Г. | - | «Теләче РДВБ» ДБУ башлыгы (килешү буенча); |
| Ярмиев И.З. | - | «Татавтодор» ААҖ Арча филиалы Теләче участогы башлыгы (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«27» 03 2023 № 64
карарына 2 номерлы кушымта

Торак пунктлар территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык үткәрү буенча чаралар планы

| № т/б | Чаралар исеме | Башкару вакыты | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Торак пунктлар, предприятиеләр һәм учреждениеләр, башка гомуми кулланылыштагы урыннар территорияләренең экологик торышын анализлау | 05.04.2023 кадәр | Район Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| 2. | Районның барлык торак пунктларында территорияләрне төзекләндерү һәм санитар чистарту мәсьәләләре буенча җыеннар (җыелышлар) үткәрү | 15.04.2023 кадәр | Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 3. | Авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив-хокукый актлары нигезендә оешмалар, милекчеләр һәм арендаторлар арасында территорияләрне җыештыру һәм тоту чикләрен килештерү | 05.04.2023 кадәр | Авыл җирлекләре башлыклары, авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 4. | Территорияләрне санитар чистарту һәм төзекләндерү эшләрен оештырырга | Атна саен чәршәмбе һәм шимбә | Авыл җирлекләре башлыклары, район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 5. | Һәр торак пунктта:<br>- торак пунктлар, урамнар, йорт номерлары исемнәре белән күрсәткечләрне, шулай ук предприятиеләр һәм учреждениеләр, сәүдә нокталары исемнәре белән элмә такталарны ремонтлау буенча эш алып бару, кирәк булганда аларны яңарту;<br>- урамнарны, предприятие һәм учреждениеләр территорияләрен яшелләндерү буенча чаралар үткәрү;<br>- яңа клумбалар җитештерү һәм аларны карау;<br>- су җыю скважиналарының санитар-яклау зонасы киртәләрен норматив хәлгә китерү;<br>- калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру барлыкка килүгә юл куймау;<br>- торак пунктлар урамнары буенча транспорт хәрәкәтен чикләү; | Икеайлык чорында | Авыл җирлекләре башлыклары, предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләре, шәхси эшмәкәрләр (килешү буенча) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - үләт базларын тиешенчә санитар-техник халәткә кертү, коймалар урнаштыру һәм аншлаглар кую;<br>- зиратларны чүп-чардан, калдыклардан, корып беткән ботаклардан чистарту | | |
| 6. | Юл буе полосаларын, көтү павильоннары территорияләрен чүп-чардан арындыру | Даими | Авыл җирлекләре башлыклары, «Татавтодор» ачык акционерлык җәмгыятенең Арча филиалы Теләче участогы (Ярмиев И.З.), юл буе җир кишәрлекләре милекчеләре (килешү буенча) |
| 7. | Муниципаль берәмлек чикләре күрсәткечләрен ремонтлау һәм төзекләндерү:<br>- Саба муниципаль районы ягыннан Казан-Шәмәрдән автомобиль юлында | 20.04.2023 кадәр | Иске Җөри авыл җирлеге (Мараков Р.Р.) (килешү буенча) |
| | - Арча муниципаль районы ягыннан Арча-Теләче автомобиль юлында чик күрсәткечләре | | Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге (Мәхмүтов Ф.Р.) (килешү буенча) |
| | - Казан шәһәре ягыннан Казан-Яр Чаллы автомобиль юлында | | «Агролак» ҖЧҖ, Шәтке авыл җирлеге (Кадыйров Ф.Г.) (килешү буенча) |
| | - Яр Чаллы шәһәре ягыннан | | «Теләче агрохимсервис» ААҖ (Хәкимов Л.С.), Олы Нырсы АҖ (Гиниятов Р.М.) (килешү буенча) |
| | - Мамадыш муниципаль районы ягыннан Теләче-Мамадыш автомобиль юлында | | Әбде АҖ (Рәхмәтуллин Н.Р.) (килешү буенча) |
| 8. | Теләче авылы торак пункты күрсәткечләрен реконструкцияләү:<br>- Саба муниципаль районы ягыннан;<br>- Казан шәһәре ягыннан;<br>- Арча муниципаль районы ягыннан;<br>- Ачы авылы ягыннан | 20.04.2023 кадәр | Теләче авыл җирлеге (Мараков И.Р.) (килешү буенча) |
| 9. | Теләче авылы янындагы территорияне төзекләндерү | 08.05.2023 кадәр | Теләче авыл җирлеге (Мараков И.Р.) (килешү буенча) |
| 10. | Кагыйдә бозучыларны административ җаваплылыкка җәлеп итеп, санитария нормаларының, территорияләрне тышкы төзекләндерү нормаларының үтәлешен тикшерү буенча рейдлар үткәрү | Атна саен шимбә көнне | Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча), район штабы секретаре (Насыйбуллина В.Г.) |
| 11. | Район штабы утырышларында Икеайлыкны үткәрү планы буенча чараларны үтәүнең барышын карау | Атна саен | Район штабы башлыгы (Хәмидуллин И.Х.) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12. | «Теләче» газетасы битләрендә, Интернет челтәрендәге сайтта Икеайлык үткәрүнең барышы турында пропаганда алып бару һәм мәгълүмат бирү | Атна саен | «ТАТМЕДИА» АЖ филиалы (Хужин Л.Й.) (килешү буенча) |
| 13. | Бөек Ватан сугышы ветераннары, инвалидларның коймаларын, капкаларын ремонтлау һәм буяу | 25.04.2023 кадәр | Авыл җирлекләре башлыклары, предприятие һәм оешма җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 14. | Су саклау зоналары һәм яр буе полосаларының куелган билгеләренә ревизия үткәрү | 29.04.2023 кадәр | Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 15. | Теләче авылы янәшәсендәге ККК полигонына калдыклар кабул итү ККК полигоны эшчәнлегенең гамәлдәге законнар нигезендә гамәлдәге нормативлары нигезендә | Икеайлык чорында | «Мишә» ҖЧҖ (килешү буенча) |
| 16. | Район торак пунктларыннан каты коммуналь калдыкларны вакытында чыгару (ККК чыгаруның расланган графиклары нигезендә) | Икеайлык чорында | «ТКХП» ИК» ҖЧҖ (килешү буенча) |
| 17. | Торак пунктларда юл буйларында электр линияләре терәкләрен буяу | Икеайлык чорында | «Челтәр компаниясе» ААҖ филиалы Теләче РЭС (Якупов Р.Ш.), авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 18. | Урам-юл челтәрендәге чокырларны ямау | Икеайлык чорында | Авыл җирлекләре башлыклары, авыл башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 19. | Күпфатирлы йортларда яшәүчеләрнең йорт яны территорияләренең чисталыгын тәэмин итү, йорт яны территорияләренең өмәләр графигын билгеләү мәсьәләләре буенча җыелышлар үткәрү | 25.04.2023 кадәр | «Теләче районы идарәче компаниясе» ҖЧҖ, Үзәк авыл җирлеге башлыгы, Теләче авыл башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| 20. | ККК җыю контейнерларына һәм контейнер мәйданчыкларына ревизия үткәрү, кирәк булганда ремонт ясау һәм буяу | Икеайлык чорында | Теләче авылы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| 21. | Оешмаларның исемнәре элмә такталаарын норматив халәткә китерү | 15.04.2023 кадәр | Предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 22. | Су объектларының, скверларның, паркларның, балалар мәйданчыкларының су саклау зоналарын санитар чистарту буенча чаралар үткәрү | Икеайлык чорында | Авыл җирлекләре башлыклары, авыл башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 23. | Инструктаж үткәрү - куркынычсызлык техникасы һәм хезмәтне саклау буенча максатчан | Өмә башланыр алдыннан | Предприятие, оешма җитәкчеләре, җаваплы затлар |